# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ
# К А Р А Р

14.03.2016 № 27

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге территориясендә 2016 елның 13 мартындагы җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 55,56 статьялары нигезендә Арча районы территориаль сайлау комиссиясе участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында беренче нөсхәсе мәгълүматлары нигезендә җирле референдум нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча беркетмә төзеде:

«2016 елда Яңасала авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) 1әм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Яңасала авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда юлларны вак таш-лау; | 60000 |
| 2 | Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру | - вакытлыча корыла торган урыннарны тоту, Яңасала авыл җирлеге составына кердә торган барлык торак пунктларда каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгаруны оештыру; | 6000 |
| 3 | Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү | - Янга-Сала авылында янгын сүндерү гидранты урнаштыру (шул исәптән суүткәргеч торба салу);<br>-Каенсар авылында янгын сүндерү гидранты урнаштыру. | 40000<br>16000 |
| | | **Барлыгы:** | **122000** |

Референдум нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 350 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә референдумда катнашучылар саны-336, бу 96,00 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 280 референдумда катнашучы тавыш бирде, бу 83,33 % тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 56 кеше тавыш бирде, бу 16,67 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча районы территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. «2016 елда Яңасала авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертү (түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 70 яшьтән өлкәнрәк гражданнар өчен) 1әм акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| № | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар | тоту өчен акча күләме /сум |
|---|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | - Яңасала авыл җирлеге составына керүче барлык торак пунктларда юлларны вак таш-лау; | 60000 |
| 2 | Каты коммуналь калдыкларны җыю һәм транспортлау эшчәнлеген оештыру | - вакытлыча корыла торган урыннарны тоту, Яңасала авыл җирлеге составына керә торган барлык торак пунктларда каты коммуналь калдыкларны җыю һәм чыгаруны оештыру; | 6000 |
| 3 | Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү | - Янга-Сала авылында янгын сүндерү гидранты урнаштыру (шул исәптән суүткәргеч торба салу);<br>-Каенсар авылында янгын сүндерү гидранты урнаштыру. | 40000<br>16000 |
| | | **Барлыгы:** | **122000** |

соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru. http:pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре Л. И. Нурмиева